РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 ноябрь 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Кымышлы Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. 2023 елның 02 декабрендә 13сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Камышлы-Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Камышлы – Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2023 елның 02 декабрендэ 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны-Камышлы Күл авылы, Ленин ур., 11Б, Камышлы Күл мәчете бинасы;

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча бирергә: Туйкә авылы, Җәлил урамы, 19 йорт, Камышлы Күл авылы, Ленин ур., 11Б;
- сайлау хокукына ия Камышлы Күл торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Камышлы Күл торак пунктына халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаилә әгъзалары мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләр, ирекле хезмәткәрләр, контракт буенча хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә махсус хәрби операциядә катнашучылар дан тыш, гражданнарның аерым категорияләре өчен: 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәкләр, күп балалы гаиләләр өчен түләүне бер тапкыр киметеп 250 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Камышлы Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы

- Камышлы Күл торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (тракторчыга механикалаштырылган кар җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү, Камышлы Күл авылында юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү);

- Камышлы Күл авылы урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны ,яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар жуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл, Ленин ур., тукталыш янында;

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова